РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

№12 «28» апреля 2022 г.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 12 мартындагы 225 номерлы «Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәтне инвентаризацияләүне уздыру тәртибен һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибен раслау турында» карарын гамәлгә ашыру хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

1. МКУ «Теләче муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» н Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 12 мартындагы 225 номерлы «Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәтне инвентаризацияләүне уздыру тәртибен һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибен раслау турында» карарын (алга таба - Тәртип) гамәлгә ашыру буенча җаваплы орган итеп билгеләргә.

2. МКУ «Теләче муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» Тәртип нигезендә эшләргә, муниципаль мөлкәтне инвентарьлаштыру нәтиҗәләрен гомумиләштерергә, муниципаль берәмлек милкендәге файдаланылмый торган күчемсез милек объектлары исемлеген расларга, файдаланылмау сәбәпләрен күрсәтеп, төркемнәргә бүләргә һәм инвентаризация нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ел саен хисап елының 10 декабренә кадәр җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.Х. Хәмидуллинга йөкләргә .

Н.Н. Хаҗипов